РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» декабрь 2018 ел Буа шәһәре № 376/ИК-п

Социаль файдаланыштагы
торак фондның торак урыны
найм килешүе буенча тәкъдим ителүче
торак урын мәйданының хисаплау
нормасы һәм торак урынның
гомуми мәйданы зурлыгы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14, 50, 91.3, 91.15 статьялары, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль найм шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 7.1, 44 статьялары нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

Торак урынның хисаплау нормасын (торак урын мәйданының минималь зурлыгын, шуңа карап гражданнарның социаль файдаланыштагы торак фондының торак урыннары найм килешүе буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ буларак, аларны исәпкә кую максатында торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе ачыклана) торак урын гомуми мәйданының гаиләнең һәр әгъзасына 18 кв. м. күләмендә билгеләргә.

2. Социаль файдаланыштагы торак фондының торак урыны найм килешүе буенча тәкъдим ителгән торак урын (алга таба – тәкъдим ителгән торак урын) гомуми мәйданының зурлыгын бер кешегә исәпләгәндә түбәндәгечә билгеләргә:

- 33 кв. м – ялгызы яшәгән гражданинга;
- 21 кв. м – ике кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;
- 18 кв. м – өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына.

Тәкъдим ителгән торак урын гомуми мәйданының зурлыгын Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда арттырырга рөхсәт ителә.

Тәкъдим ителгән торак урын гомуми мәйданының зурлыгын киметү гражданнар ризалыгы (гаризасы) буенча рөхсәт ителә, әмма торак урын гомуми мәйданының бер кешегә хисаплау нормасыннан азрак булырга тиеш түгел.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов